**Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының «муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 25 июлендәге 557 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының 25.07.2019 ел, № 557 карары белән расланган муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.2 пунктта «1 нче кушымтаның»сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 2 бүлегендәге 2.9 пунктының 3.1 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

3) 2 бүлегенең 2.9 пунктындагы 8 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан, моңа мондый җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма, андагы урыннар, төгәлләнмәгән төзелеш объекты милекчесе яисә мондый җир кишәрлегенең Хокук иясе җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән мөрәҗәгать иткән очраклар керми";

4)2 бүлегенең 2.9 пунктындагы 13 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата Россия Федерациясе Җир Кодексының 39.18 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару өчен җир кишәрлеге бирү турында хәбәр басылып чыкты һәм урнаштырылды»;

4) 1 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.А. Гасыймов**